ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# Габдулла Тукай

## Әсәрләр

Академик басма
Алты томда

## 5 том

Мәсәлләр. Балалар өчен хикәяләр
Автобиографик повесть. Юлъязмалар
Хатлар
(1903–1913)

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2016

УДК 821.512.145-3/4
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Т72

Редколлегия:
*К. М. Миңнуллин (җитәкче), Т. Н. Галиуллин, Д. Ф. Заһидуллина, Х. Й. Миңнегулов, Р. Ф. Рахмани, З. З. Рәмиев, И. К. Сәгъдәтшин, Р. Г. Фәйзуллин, Н. Ш. Хисамов*

Төзүчеләр, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр:
*Гөлназ Хөснетдинова, Гөлчирә Ханнанова*

Фәнни мөхәррире
*Зөфәр Рәмиев*

**Тукай, Г. М.**

Т72 Әсәрләр : 6 томда / Габдулла Тукай. — Академик басма. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2011—2016.
ISBN 978-5-298-02041-1
5 т. : мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903—1913) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Г. А. Хөснетдинова, Г. М. Ханнанова. — 2016. — 415 б.
ISBN 978-5-298-02996-4

Әлеге томда татар әдәбияты классигы Габдулла Тукайның мәсәлләре, балалар өчен язган хикәяләре, автобиографик повесте, юлъязмалары һәм хатлары хронологик тәртиптә туплап бирелде. «Кушымта»да беренче мәртәбә мәсәлләрнең «Әлгасрелҗәдид» журналында басылган вариантлары, Тукайга язылган хатлар, шагыйрь белән аралашкан, хат алышкан замандашларының истәлекләре урын алды.

Китап Г. Тукай иҗаты белән кызыксынучылар игътибарына тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145-3/4
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-02996-4 (5 т.)
ISBN 978-5-298-02041-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2016
© Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2016

Гаебем булса, тик азрак иркенрәк язганмын. Бу ни бәла бу? Мин Каракдан да начар булырмын дип уйламаган идем...»

Мөхәррир шулай мыгырдап торганда, кисәкдән җәһәннәм төтеннәре арасыннан күзләре яшендәй ялтыраган, кулында гөрзи, чәч араларында җыланнар ыжылдап тора, кап-кара йөзле, арыслан тырнаклы бер зобани, чыгып, Мөхәррир өстенә утлар чәчеп: «И бәдбәхет! Синме дингә тарайдың? Синме нәфесгә охшаган эшне шәригать куша дидең? Һәм син Карак илә үзеңне бер күрмәкче буласыңмы? Ул Каракның зарары үзе тере вакытда гына булды, әмма син үлдең, сөякләрең череп туфрак булдың, синең бозыклыкларың, синең усаллыкларың дөнья гомере беткәнче барды; кайчан кояш чыкса, син калдырган усаллык, бозыклар да дөньяга чыга иде. Синең җимеш суларың илә исереп сугышып, үлтерешеп җөрүчеләр, синең хатын-кыз качмасын дигәнгә иярүчеләр, зина, фәхешлекләр илә башлары әйләнеп, дөнья-ахирәт бәхетләрендән коры калганнар. Шул үлтерешүчеләрнең бер тамчы канына, җылаучыларның бер къәтрә күз яшенә — һәммәсенә син гаеплесең; синме Аллаһы Тәгаләгә каршы Нәмруд[1] кеби коралланасың!» — дип орышып, шелтәләп, Мөхәррирнең өстенә казан капкачын шалт итдереп япды да китде.

---

*Гөрзи* — чукмар.
*Къәтрә* — тамчы.

## ГАУВАСЛАР

Иске заманның бер Падишаһсы үзенең кәкре фикере илә гыйлемнең файдасыннан күбрәк зарары барлыгын табды. Ул гыйлем кешенең күкрәген черетә, кулларын нечкәртә, имеш. Әгәр дә үз мәмләкәтендә булган барча галимнәрне кудырса, үзен үзе бик зур изгелек кыйлучылардан санамакчы булды. Падишаһ үзе дә, бу фикеренең дөрестлекендә шөбһәләнеп, шул фикер тугрысында халыкларның ни әйткәнен белер өчен, галимнәрнеме, белмим, җаһилләрнеме, — берничә йөз кешеләр җыеп, бер мәҗлес ясады.

Халык гыйлем тугрысында төрлесе төрле сүз сөйли иде. Кайсы әйтә: «Аллаһы Тәгалә безгә, гыйлем эстәсеннәр дип, гакыл биргән. Безнең атамыз Адәм галәйһиссәлам гакылы илә фәрештәләрдән өстен булган, һәм адәмнәр гыйлем өчен бирелгән гакыллары илә яратылмышларның иң хөрмәтлесе булганнар. Адәмнәрдән кат-кат көчле хайваннар, гакыллары булмаган сәбәпле, адәмнәргә та кыямәт кол булганнар», — ди.

Кайсылары әйтә: «Халык укыган саен бозылалар, динне җиңелгә саныйлар, муллаларга да тәгъзимдә косурлык итәләр, хаҗилар алып кайткан Мәрьям ана чәчен хөрмә агачының мунчаласы диләр һәм шул хәерсез гыйлем булмаса, Әндәлес дәүләтләре[1], холәфаи Габбасия мәмләкәтләре хәрап булмас иде», — ди.

Җыелган кешеләрнең очсыз-койрыксыз сүзләре һәм гыйлем вә җәһел мәсьәләсе хосусында язылган тау-тау кәгазьләре Падишаһның башын гына чуалталар иде. Падишаһ, бу мөшкил мәсьәлә хакында болай гына сөйләүләргә канәгать итмичә, борынгыдан да зуррак мәҗлес ясады. Бу мәҗлескә дә җыелган халык, әлбәттә, тик торырга җыелмаганнар. Тагы зур тавыш, тагы зур кычкырышлар күтәрелә башлады.

Шул арада халык эчендән бер Карт чыкды. Бу Картның чәһрәсендән, йөзендән сакалны тегермәндә генә агартмаганлыгы аңлашыла иде. Падишаһ, бу Картка илтифат итеп, Картдан бу мөшкил мәсьәләне чишүен үтенде.

Карт, баш өстенә дип, мәсьәләне чишмәкче булып, шуңа тәгаллекъләрәк бер хикәяткә керешеп, диер ки: «Һиндстанда бөтен гомерен ярлылыкда, хәсрәтдә кичергән бер Балыкчы

---

*Гауваслар* — диңгез төбенә чумып, энҗе-мәрҗән эзләүчеләр.
*Җаһилләрнеме* — наданнарнымы.
*Та кыямәт* — кыямәткә, дөнья беткәнгә чаклы.
*Тәгъзимдә косурлык итәләр* — тиешенчә олыламыйлар.
*Җәһел* — наданлык.
*Чәһрәсендән* — йөз, битләреннән.
*Тәгаллекъләрәк* — бәйләнешлерәк.

карт бар иде. Бу Карт үлгәч, артында өч баласы калды. Бу балалар бу көнгә кадәр тарлыкда, мохтаҗлыкда вакыт үткәргәннәрен хисаплап һәм, аталарының һөнәрен яратмыйча, болар диңгездән тагы да зур байлыклар алмакчы булдылар. Инде диңгездән балык түгел, энҗе алырга уйладылар.

Болар, уйлары буенча, гауваслык (диңгезгә чуммак) гыйлемене бик яхшы үгрәнеп, һәр өчесе диңгезгә чума башладылар. Шулай булса да, бу өч агай-эненең бәхетләре төрлечә иде. Бер борадәр калган икесендән ничә градус ялкау, аның диңгезгә кереп, аягын да җүешләтәсе килми иде. Шуның өчен һәрдаим җар читләренә дулкын илә чыкган энҗеләрне генә җыядыр һәм шул кәсебе илә көчкә генә тамак туйдырадыр иде.

Икенче борадәр, тырышып, көчен-куәтен кызганмыйча һәм диңгезнең төпсез җирләренә бармыйча, кадәре хәл генә чумып, энҗеләрне җыеп, үзенең байлыгын сәгать саен артдырадыр иде.

Өченчесе, күңелендә «Дөрест, диңгезнең читләренә чумсаң да азлап-азлап кына энҗе алып була, әмма болай азлап алган мал илә тиз баеп булмас» уен яшереп, диңгезнең иң уртасына чумарга кисдергән иде. Моның уенча, тирән җирдә хисапсыз хәзинәләр, байлык таулары бар һәм анда, бер энҗе генә булмаенча, гәүһәр, якут, мәрҗән һәм зөбәрҗәтләр дә тулган. Бу борадәр, үзенең гыйлеменә ышанып һәм чуммак фикеренә әсир булып, диңгезнең кайда каралып торган төпсез җире булса, шуны эзләп, ахырда табып, бар көче илә чумып китде. Бәхетсез Җекет диңгезнең төбенә җитә алмады, диңгез төбендәге байлыкларның һәммәсендән кыйбатлырак җанындан аерылды. Менә, Падишаһым, гыйлемдә файдалар күп булса да, бәгъзеләр гыйлемне урынсыз истигъмаль итеп, гыйлемдән зарар да табалар», — дип, Карт хәтме кәлям әйләде.

---

*Борадәр* — ир туган.
*Истигъмаль итеп* — кулланып.
*Хәтме кәлям әйләде* — сүзен тәмамлады.